СОВЕТ
СРЕДНЕАТЫНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Центральная , д. 2а, д.Нижние Аты,
Арский муниципальный район, 422016

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УРТА АТЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Үзәк урамы, 2 йорт, Түбән Аты авылы,
Арча муниципаль районы, 422016

**Тел. (84366)507-35, факс (84366)507-35. E-mail: Sat .Ars@tatar.ru**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Урта Аты авыл җирлеге башлыгы карары**

**1 ноябрь 2024 ел** **№ 7**

**Арча муниципаль районы Урта Аты авыл җирлеге Кылачы авылында гражданнарның үзарасалым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль Урта Аты авыл җирлеге Уставының 25 статьясы нигезендә, Арча муниципаль районы Урта Аты авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башлыгы Карар бирде:

1.Арча муниципаль районы Урта Аты авыл җирлеге Кылачы авылында , Аяк киеме урамы, 17 йорт адресы буенча гражданнарның үзарасалым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча 2024 елның 15 ноябрендә 10 сәгать 00 минутта халык җыенын билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарылучы түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Сез 2025 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Урта Аты авыл җирлеге Кылачы авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 500 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан тыш, 250 сум күләмендә үзара салым кертү, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (алар белән бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту; (вак таш сатып алу)
- тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар урнашкан мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәсен

тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау ( урамнарны яктырту челтәрләрен ремонтлау, шул исәптән яктырткычлар, лампалар, изоляцияләнгән чыбыклар, таймерлар, счетчиклар, автоматлар, җибәргечләр сатып алу һәм урнаштыру)

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

«ӘЙЕ» «КАРШЫ»»

3.Арча муниципаль районы Урта Аты авыл җирлеге Кылачы авылында гражданнарның үзарасалым акчаларын кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы итеп Урта Аты авыл җирлеге башкарма комитетын билгеләргә.

4. Әлеге карарны халык күп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларына ТР, Арча районы, Кылачы авылы, Аяк киеме урамы, 17 йорт адресы буенча, интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Рәсми хокукый мәгълүмат порталында http:pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Урта Аты авыл җирлеге башлыгы Р.Х.Батталова

СОВЕТ СРЕДНЕАТЫНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ